**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

“25” гыйнвар 2019 ел

**Карар № 1**

**Кышлау авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясенең Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында” Указы нигезендә, авыл җирлегендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотик чаралар куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән 2019 елга чаралар планы һәм авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Кышлау авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Шакирова Р.Ф.

Әтнә муниципаль районы Кышлау
авыл җирлеге башлыгының
2019 елның 25 гыйнварындагы
1 номерлы карары белән расланды

Кышлау авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планы

| №<br>п/п | Башкарылучы чаралар | Башкару срогы | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1. Наркотикларны законсыз куллану һәм наркомания таралуны кисәтү | | | |
| 1.1 | Хокук саклау һәм сәламәтлек саклау органнары хезмәткәрләренең наркотикларны законсыз куллануның хокукый һәм медицина аспектларын яктырту максатында мәктәп укучылары, авыл яшьләре белән очрашуларны системалы рәвештә уздыру. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе,<br>Яна Шашы гомуми белем бирү мәктәбе<br>Кышлау авылы<br>РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге<br>(килешү буенча) |
| 1.2 | Яшьләр акцияләре үткәрү:<br>«Наркотикларсыз дөнья» акциясе<br><br>Бөтендөнья сәламәтлек көненә багышланган Акция<br><br>«Без СПИДка каршы» протест акциясе | май<br><br>июнь<br><br>декабрь | Яна Шашы гомуми белем бирү мәктәбе<br>Кызыл Утар авыл клубы<br>Кышлау авылы мәдәният йорты<br><br>Кызыл Утар авыл клубы<br>Кышлау авылы мәдәният йорты<br><br>Кызыл Утар авыл клубы<br>Кышлау авылы мәдәният йорты<br>(килешү буенча) |
| 1.3 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән спорт ярышлары, турнирлар үткәрү | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе,<br>Кышлау башлангыч белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы<br>(килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. Наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча чаралар | | | |
| 2.1 | Наркотиклы үсемлекләрнең законсыз чәчүлекләрен ачыклау буенча оператив-тикшерү чараларын уздыру, наркотик әзерләүчеләрне, аны йөртүчеләрне тоткарлау. | май-октябрь | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.2 | Авыл җирлеге территориясендә кыргый киндерне һәм законсыз чәчүлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча чараларны тормышка ашыру | июнь - октябрь | Авыл җирлеге администрациясе,<br>РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.3 | Наркотик чаралар кулланучы затлар турында исәп-хисап мәгълүматларын тикшерүне системалы рәвештә гамәлгә ашыру | Ел дәвамында | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге<br>Кышлау ФАПы,<br>Кызыл-Утар ФАПы (килешү буенча) |
| 2.4 | Наркотик матдәләр булган үсемлекләрне законсыз рәвештә үстерүгә, шулай ук җәмәгатьчелек арасында наркотиклар куллануга карата тискәре мөнәсәбәт булдыруга, административ һәм җинаять җаваплылыгын аңлату максатыннан Авыл җирлеге торак пунктларында яшәүчеләр белән аңлату эшләре, җыелышлар үткәрү. | апрель - май | Авыл җирлеге администрациясе,<br>РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.5 | Авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнарының килүен исәпкә алу һәм контрольдә тоту. | ай саен | Авыл җирлеге администрациясе,<br>Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча миграция пункты (килешү буенча) |
| 3.Наркотикларны медицинаныкы булмаган куллануга юл куйган затларны дәвалау, эшкә яраклылыгын торгызу һәм реабилитацияләү | | | |
| 3.1 | Наркотиклар, психотроп матдәләр | Ел дәвамында | РФ Эчке эшләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кулланучы гражданнарны ачыклау | | министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге, Кышлау ФАПы, Кызыл-Утар ФАПы (килешү буенча) |
| 3.2 | Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә наркотик һәм башка психотроп матдәләргә ирекле үтеп керүне булдырмау. | Ел дәвамында | Кышлау ФАПы Кызыл-Утар ФАПы |

Авыл җирлеге башлыгы: Шакирова Р.Ф.